КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 июль г.Казань № 692

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнарның алдынгы тәҗрибәсен тарату, җәмгыятьтә гаиләнең ролен һәм абруен, культура дәрәҗәсен арттыру һәм халыкка граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнарның иң яхшы һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә ия белгечләрен ачыклау һәм хуплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсы турындагы нигезләмәне;

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне;

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының конкурс комиссиясе составын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенә «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт

теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсын биш елга бер тапкыр оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 18 июль, 692 нче
карары белән расланды

## «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсы турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Нигезләмә «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурс Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнарның (алга таба – ГХАТ органнары) алдынгы тәҗрибәсен тарату, җәмгыятьтә гаиләнең ролен һәм абруен, культура дәрәҗәсен арттыру һәм халыкка граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органнарның иң яхшы һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә ия белгечләрен ачыклау һәм хуплау максатларында үткәрелә.

3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары ярдәмендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Конкурс биш елга бер тапкыр ике – зона һәм финал этапларында үткәрелә.

5. Конкурсның зона этабы Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында Идарә боерыгы белән расланган график буенча билгеләнгән зоналарга бүленеш нигезендә үткәрелә.

6. Зона этабының конкурс комиссиясе составы Идарә тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалары, мәдәният эшлеклеләре арасыннан төзелә.

7. Конкурсның зона этабы ГХАТ органнары җитәкчеләре һәм белгечләре (алга таба – ГХАТ органнары хезмәткәрләре) арасында үткәрелә. Конкурсның зона этабын үткәрү тәртибе Идарә боерыгы белән билгеләнә.

8. Конкурсның финал этабы конкурсның зона этабында җиңүчеләр арасында (җыелган балларның саны буенча) үткәрелә.

Конкурста сайлап алу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан «Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) төзелә, ул конкурсның финал этабында даими эшләүче эшче орган булып тора.

9. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Никахлашу тантанасының иң яхшы алып баручысы»;
«Исем бирү тантанасының иң яхшы алып баручысы»;
«Гаилә тормышы юбилярларын тәбрикләү тантанасының иң яхшы алып баручысы».

10. Конкурс йомгаклары буенча һәр номинациядә өч җиңүче – 1, 2, 3 дәрәҗә лауреатлары (алга таба – конкурс лауреаты) билгеләнә.

## II. Конкурсны әзерләү һәм үткәрү тәртибе

11. Конкурс үткәрү елында конкурс үткәрү турында белдерү Идарә тарафыннан Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Идарәнең рәсми сайты) урнаштырыла.

Конкурс үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

конкурста катнашучыларга карата куела торган таләпләр, конкурс биремнәренең формалары;

конкурста катнашу өчен документлар тапшыру тәртибе һәм срогы;

конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм срогы;

конкурс турында тулы мәгълүмат алу чыганагы турында белешмәләр (телефон, электрон почта адресы).

12. ГХАТ органнарында кимендә ике ел эш стажы булганда конкурста катнашу өчен документлар тапшырыла торган елга кадәрге ел дәвамында дисциплинар җәзалары булмаган ГХАТ органнары хезмәткәрләренә конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

13. Конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән 30 көн эчендә Идарә тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары ярдәмендә бу Нигезләмәнең 17 пункты нигезендә конкурста катнашучыларның документлары кабул ителә.

14. Конкурста катнашучыларны тәкъдим итү Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының ГХАТ органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

15. Конкурста катнашучыларны билгеләү максатларында ГХАТ органнары җитәкчеләре тарафыннан сайлап алу процедураларын үткәрү оештырыла.

16. ГХАТ органыннан конкурста катнашучыларны билгеләү буенча сайлап алу процедураларының формасы һәм тәртибе тиешле ГХАТ органы тарафыннан билгеләнә.

17. Сайлап алу процедураларын уңышлы узган һәм конкурста катнашучы буларак билгеләнгән ГХАТ органы хезмәткәре Идарәгә кәгазьдә түбәндәге документларны тапшыра:

бу Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча конкурста катнашу турында гариза;

бу Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча катнашучының анкета мәгълүматлары һәм ирешкән казанышлары күрсәтелгән, Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты җитәкчесе белән килештерелгән ГХАТ органы җиткәчесенең үтенечнамәсе;

гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алу тантанасын үткәрүдә катнашучының шәхси сценарие / гаилә тормышы юбилярларын тантаналы котлау, альбомнар, видеоязмалар, фотографияләр һәм башка материаллар;

конкурста катнашучының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмавы турында белешмә кәгазе;

массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Идарә боерыгы белән расланган форма буенча конкурста катнашуга бәйле конкурста катнашучы турындагы мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

18. Бу Нигезләмәнең 17 пунктында күрсәтелгән документларның барысын да тапшырмау яки документларны бу Нигезләмә таләпләрен бозып тапшыру ГХАТ органы хезмәткәренә аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора. Документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Идарә бу хакта ГХАТ органы хезмәткәренә кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә хәбәр итә.

19. Конкурс бу Нигезләмәнең 13 пунктында каралган документларны кабул итү срогы тәмамланган көннән 120 көн эчендә үткәрелә.

20. Конкурста катнашучылар 10 баллы система буенча бәяләнә. Конкурс лауреатларын билгеләү критерийлары:

а) тышкы кыяфәте (костюм, прическа, аксессуарлар);

б) ораторлык осталыгы (сөйләм куелышы, тембр, дикция, ишарәләр, алып бару стиле, артистизм);

в) эстетиклык, гомуми культура дәрәҗәсе, сәнгатьчә башкарылыш;

г) психологик контакт, дәүләт теркәвенә алу тантанасында катнашучылар белән үзара аңлашу атмосферасына ирешү;

д) дәүләт теркәвенә алу яки котлау тантанасының индивидуаль сценарием бәяләү, аның оригинальлеге, яңалыгы, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны җайга сала торган норматив хокукый актларга туры килүе;

е) дәүләт теркәвенә алу яки котлау тантанасын үткәрүнең гомуми оештырылышы (дәүләт теркәвенә алуның музыка белән бизәлеше һәм бөтенлеге).

21. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучыларны тапшырылган документлар һәм материаллар, гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу / гаилә тормышы юбилярларын котлау тантанасын карау нигезендә бәяли. Конкурста җиңүчеләрне – финалчыларны билгеләгәндә барлык җыелган балларның суммасы исәпкә алына.

## III. Конкурс нәтиҗәләре

22. Конкурс нәтиҗәләре конкурс комиссиясенең йомгаклау утырышында аның карары белән билгеләнә, ул утырыш үткәрелгән көннән соң өч көн эчендә беркетмә белән рәсмиләштерелә.

23. Конкурс лауреатлары «Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» дипломы һәм түбәндәге күләмдәге акчалата бүләк белән бүләкләнә:

1 дәрәҗә лауреатлары – 30 мең сум;

2 дәрәҗә лауреатлары – 20 мең сум;

3 дәрәҗә лауреатлары – 10 мең сум.

24. Конкурс нәтиҗәләре конкурс лауреатларын бүләкләгән көннән биш көн эчендә Идарәнең рәсми сайтында урнаштырыла, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

25. Конкурсны финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

26. Конкурс үткәрүне оештыру һәм техник яктан тәэмин итү Идарә тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча конкурс комиссиясенә

______________________________________
(конкурста катнашучының вазыйфасы, эш урыны,

______________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
__________________________________ нан (тан)
(элемтәгә керү өчен телефон)

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсында катнашу турында
гариза

«Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсында ________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________ номинациясендә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

Конкурс шартлары белән таныштым һәм килешәм.

Түбәндәге документларны (альбомнар, видеоязмалар, фотосурәтләр һәм башка материаллар) терким:

1. ______________________________________________________________________
2. ______________________________________________________________________
3. ______________________________________________________________________
4. ______________________________________________________________________

| ____________________ | ______________________________ | __________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (конкурста катнашучының имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсы турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсында катнашу турында
үтенечнамә

______________________________________________________________
(гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле орган исеме)
______________________________________________________________
______________________________________________________________ номинациясендә

| | |
|---|---|
| Конкурста катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | |
| Туу датасы һәм урыны | |
| Эш урыны, вазыйфасы | |
| Билгеләнү датасы | |
| Классны чин (булганда) | |
| Гомуми эш стажы | |
| Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле органда эш стажы | |
| Бүләкләр һәм бүләкләүләр (булганда) | |
| Дисциплинар җәзалар (әйе/юк) | |
| Өй адресы, элемтәгә керү өчен телефон | |

Казанышлар һәм өстәмә мәгълүматлар ______________________________
______________________________________________________________

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсында катнашучы буларак сайлап алу процедураларын узган ______________________________
(конкурста катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
билгеләнде.

| | | |
|---|---|---|
| (дата) | (граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтле орган җитәкчесе имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |
| (дата) | (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе имзасы) | (инициаллары, фамилиясе) |

М.У.

________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 18 июль, 692 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының конкурс комиссиясе турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының конкурс комиссиясе – «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының (алга таба – конкурс) финал этабын үткәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан төзелгән даими гамәлдәге күмәк орган.

2. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Конкурс комиссиясе составына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар, мәдәният эшлеклеләре вәкилләре кертелә.

## II. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары

4. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары:
конкурс үткәрү буенча программа чараларын эшләү;
конкурсның финал этабында конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү һәм конкурста җиңүчеләрне (алга таба – лауреатлар) билгеләү;
конкурс лауреаты дипломы бланкы үрнәген раслау;
конкурс лауреатларын тантаналы бүләкләүне оештыру;
бу Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләр.

## III. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру

5. Конкурс комиссиясе конкурс комиссиясе рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм конкурс комиссиясе әгъзалары составында төзелә, алар аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

6. Конкурс комиссиясе рәисе:
конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
конкурс комиссиясе утырышларын алып бара;
конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасын, вакытын, урынын һәм көн тәртибен билгели;
конкурс комиссиясе тарафыннан кабул итә торган документларга кул куя;
конкурс комиссиясенең үз компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча карарлары үтәлешен тикшерүдә тота.

7. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

8. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс үткәрү көненә кимендә җиде көн кала конкурс комиссиясе утырышының датасы һәм көн тәртибе турында хәбәр итә.

9. Конкурс комиссиясе утырышын үткәрү турында мәгълүмат бирү конкурс комиссиясе утырышын үткәрү датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында мәгълүматны алдан хәбәр итүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән хәбәр итә.

10. Конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзаларының расланган составыннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышларда алмашу хокукыннан башка катнаша.

11. Конкурс комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 июль, 692 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручы» республика конкурсы турындагы нигезләмәнең 20 пунктында билгеләнгән критерийлар буенча һәр номинациядә конкурсның зона этабында җиңүчеләрне бәяли.

12. Һәр номинациядә конкурс лауреатлары җыелган баллар саны буенча билгеләнә.

13. Конкурс комиссиясе карары утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышы ярдәмендә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

14. Конкурс комиссиясе, тәкъдим ителгән кандидатуралар турында фикер алышып бәяләгәннән соң, конкурста катнашучыларның баллар буенча рангларга аерылган (беренчелек тәртибендә бүленгән), номинацияләргә бүленгән исемлеген төзи.

Ике һәм аннан күбрәк конкурста катнашучы бер номинациядә иң күп балл җыйган булса, лауреат конкурс комиссиясе әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән билгеләнә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Конкурста катнашу өчен документлар әлеге номинациядә катнашуга кимендә ике катнашучы биргән булса, Конкурс комиссиясе конкурсны узмаган номинациядә тану турында карар кабул итә.

16. Конкурс комиссиясенең эш нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы көненнән соң өч көн эчендә конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләре белән

рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм анда катнашучы башка әгъзалары кул куя.

17. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе утырышлары материалларының тиешле хәлдә булуы һәм аларның сакланышы өчен шәхсән җавап бирә.

18. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру һәм техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 18 июль, 692 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу тантанасының иң яхшы алып баручысы» республика конкурсының
конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллина Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы, конкурс комиссиясе рәисе |
| Әхмәтҗанов Ренат Харис улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары |
| Захаренко Ольга Николаевна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы, конкурс комиссиясе секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Барышев Александр Георгиевич | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, «Татарстан хатын-кызлары» республика иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Галәветдинов Артем Илдархан улы | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Жуйкова Изольда Павловна | «Гаилә канаты астында» Татарстан Республикасы төбәк иҗтимагый оешмасы президенты, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |
| Захарова Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Җиһаншин Фәнис Рәдиф улы | «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе актеры (килешү буенча) |
| Илдарханова Чулпан Илдус кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең «Гаилә һәм демография үзәге» аерымланган структур бүлекчәсе директоры, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Исаева Анастасия Георгиевна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Кузнецов Артем Викторович | «Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре» Татарстан Республикасы төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |
| Рыбакова Людмила Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Тарханова Алсу Абдрахман кызы | «Татарстан – новый век» – «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәтенең Югары советы башкарма комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча). |

______________________